# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Җирле үзидарә органнарына аерым категориядәге гражданнарга акчалата түләүләрне һәм өстәмә түләүне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына аерым категориядәге гражданнарга акчалата түләүләрне һәм өстәмә түләүне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2006 елның 7 декабрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш);

2) “Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2010 елның 30 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш).

**2 статья**

Әлеге Закон 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 9 декабре
№ 97-ТРЗ